РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**Исполнительный комитет «Мальбагушского сельского поселения» Азнакаевского муниципального района**
ул. Нефтяников дом 30 , с. Мальбагуш Азнакаевского муниципального района 423308,
тел 37-7-91, факс 37-7-91

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**Азнакай муниципаль районы «Мәлбагыш авыл җирлеге» башкарма комитеты**

Азнакай муниципаль районы, Мәлбагыш авылы, Нефтчеләр урамы , 30 йорт
тел 37-7-91, факс 37-7-91

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ

## КАРАР

«02» декабрь 2019 ел

№ 48

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Мәлбагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 33 статьяларына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Мәлбагыш авыл җирлегенең 02.12.2019 ел җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссия бәяләмәсе нигезендә карар бирәм:

1. Мәлбагыш авыл Советының 18.02.2014 ел №81 ( 24.12.2014 №120, 19.11.2016 №44, 04.09.2017 №61, 03.07.2018 №101, 18.03.2019 №130 карарлар редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Мәлбагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләүгә керешергә.

1.1. 1, 15, 16.1, 16.3, 16.5, 26-30, 32 статьяларны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына кертелгән үзгәрешләр белән тәңгәлләштерергә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Мәлбагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектын әзерләү буенча эш тәртибен һәм срокларын билгеләргә (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә

Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http//aznakayevo.tatar.ru.// урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өсетмдә калдырам.

Башлык И.Ә.Әхтәмова

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма
комитет карарына 1 нче кушымта
02 .12. 2019 №48

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Мәлбагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проектны әзерләү буенча эшләр башкаруның якынча вакыты**

| N | «Мәлбагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проектын әзерләү эшләрен үткәрү тәртибе | Эшләрне башкару вакыты |
|---|---|---|
| 1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү эшләрен оештыру. | 2019 елның IV кварталы |
| 2.<br><br>2.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү һәм килештерү.<br>Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең 1, 15, 16.1, 16.3, 16.5, 26-30, 32 статьяларын Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына кертелгән үзгәрешләр белән туры китерү.<br>Җирле үзидарә органына территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү бүлекне эшләргә.<br>Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын килештерүдә катнашучы хезмәтләр һәм ведомстволар кисәтүләренә шәрехләр әзерләү. | 2019 елның IV кварталы |
| 3.<br><br>3.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча фикер алышу.<br>Ачык тыңлауларны үткәрү.<br>Азнакай муниципаль районының «Мәлбагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын һәм аңа мәҗбүри кушымталарны (ачык тыңлаулар протоколы һәм ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә), җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын авыл җирлеге Советына раслауга яки кире кагуга һәм аны кабат тәкъдим итү датасын күрсәтеп эшләп бетерү турында карар кабул итү өчен Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башлыгына тәкъдим итәргә. | 2019 елның IV кварталы<br>2020 елның I кварталы |